Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



3

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАРТ * 2023 * КАЗАН

Михаил ЛАРИЧЕВ



Алмаз ХӘМЗИН

ЯШӘҮ ҖӨЕ

Дөнья үзенең кая
Барганын белми,
Күрми дә, ишетми дә –
Колакка элми.

Ә мин беләм белүен,
Хәтта бетүен...
Күрә генә алмамын
Шартлау төтенен.

Мәнсезләр күп арада –
Кайда карама...
Көчәя һәм дә арта,
Чоңгылга тарта.

Көнчелек чат ябышкан
Минең сырына.
Һич нәфесен тыялмый,
Һаман сорана.

Мәрхәмәтлек, үзара,
Күптән онытылган.
Туган туганын сата –
Акча хакыннан.

Төкереп яши берәүләр
Үз җаена, шәп.
Халкы нихәлдә икәнен
Уйласын ишәк.

Кырыла халык яуларда...
Кемдер ял итә.
Аның байлыгы афәтләр
Беткәнче җитә.

Җитә генә түгел шул,
Артып та китә.
Үзен акыллыга чутлап,
Әле ант итә.

Әхлак кайда йөри соң?
Әйтми беркем дә...
Югалтканбыз без аны –
Качкан. Үкенмә!

Үзең сайлаган язмышың,
Тормышың, көең.
Үз кулың белән чишәсең
Яшәүнең җөен...

Василий АЛЕКСАНДРОВ



ШОМБАЙ *болай диде...*



Хөрмәтле Чаян! Без гаҗәеп заманда яшибез – күз алдыбызда әкият чынбарлыкка әйләнә. Ясалма интеллектның кешене алыштыруына да күп калмагандыр. Ул инде шахмат чемпионнарын җиңә башлады, шигырьләр һәм көйләр дә яза. Роман язса да, хәзерге авторларныкыннан калышмас, мөгаен...

Г. ЧУРИЕВА

әлмәт

Укучыбызның хаты Шомбай аганы бик кызыксындырды.

– Компьютер программасы роман яза ала торгандыр, әлбәттә, – диде аксакалыбыз, **– ләкин аның үзенә нәрсәгә кирәклеген беркайчан да аңламаячак...**

Ринат АБЗАЛОВ

КАЙТЫП БАРАМ...

«Картаямын...» диеп уфтандым мин
Якынайгач яшем утызга:
Сүз катып та булмый күзем төшкән
Урамдагы чибәр кызларга...

...Кырыгы да сукты, иллесе дә –
Ләкин йөрәк «яшим» дип тибә.
Бушка узмагандыр ла бу еллар –
Акыл артты кебек, тәҗрибә...

Алар белән артты осталык та,
Кулым ята хәзер һәр эшкә.
Ләззәт бирә кылган һәрбер гамәл –
Якынаям, юкса, җитмешкә...

«Их, гомерләр» диеп зарланмыймын,
Шакыса да картлык ишеккә.
Әллә инде кайтып барам микән
«Картаям» дип йөргән яшьлеккә?..

Вячеслав ШИЛОВ



Виталий ПОДВИЦКИЙ



Бичара мөгаллимнәрне яклап

Бүгенге мәктәп тормышы яңалыклар чыгарылышларына ешрак эләгә башлады. Һәм моның сәбәбе хәзерге мәгарифнең күрелмәгән казанышларында түгел. Белем бирү йортларының көнкүреше укучыларның үз укытучыларына һөҗүм итүен яктырткан криминаль яңалыкларга охшый башлады. Хәзер укытучыны һәркем кимсетә ала – чиновник та, ата-аналар да, хәтта укучылар да. Кайчандыр җәмгыятьтә иң ихтирам ителгән һөнәр бүген ашыгыч ярдәм табибыныкы кебек, куркыныч һәм хәвефлегә әверелде.

Һәр мондый очрак үзенең оятсызлыгы белән гаҗәпләндерә. Мәскәүдә 8 нче сыйныф укучысы колагыннан наушникларын салдырып алырга батырчылык иткән өчен, 61 яшьлек физика укытучысының башына йодрыгы белән суккан. Аның Ульяновскидагы яшьтәше аннан да уздырган – 59 яшьлек математика укытучысын пычак белән чәнчегән. 9 нчы сыйныфта укучы Мәскәү әзмәвере химия укытучысының борынын һәм кулын сындырган. «Балаларның катлаулы пубертат яше», – ди психологлар, бу хәлләргә исләре дә китмичә.

Башлангыч мәктәп бәләкәчләре, өлкән сыйныфлардан үрнәк алып, тапкырлау таблицасын ятлау урынына, күбрәк йодрык белән эш итәргә өйрәнәләр. Күптән түгел Чаллыда 2 нче сыйныф укучысы класс җитәкчесенә һөҗүм итеп, аны шундый хәлгә җиткергән ки, укытучыга хәтта сырхауханәгә мөрәҗәгать итәргә туры килгән. Ә Красноярскида 3 нче сыйныфта укучы мокыт укытучысының эченә һәм аякларына типкәләгән, өстәвенә, кулын ишеккә кыскан. "Мәктәпкә ияләнү, адаптация чоры", – дип белдерә бернигә дә гаҗәпләнми торган психологлар. Ә эти каешын иң уңайлы чара дип санаган ата-аналарга шул ук психология белгечләре лаф ора: "Ярамый! Ул бала бит! Аның да хокуклары бар!" Ә хокуксыз мөгаллим, мәктәп дәфтәре кебек, барына да түзәргә тиеш булып чыга.

Уку йортларының күбесе чүпне мәктәптән чыгармауны хәерлерәк саный, шуңа күрә әлеге очраклар турындагы мәгълүмат җәмгыять өчен ябык булып кала. Аның каравы, педагоглар мәктәптә тоткарланмыйча, аннан тизрәк китү ягын карый. Яшь укытучылар исә башка юллар сайлый. Бүгенге көндә Россиядә укытучының уртача яше – 55, һәм аларның күбесе укучылар агрессиясе белән таныш.

Укытучыларны чиктән чыккан укучылардан яклау мәсьәләсе күп тапкырлар күтәрелде. Соңгы тапкыр ике ел элек. Ул чакта Гомумроссия педагоглар профсоюзы бичара мөгаллимнәр турында сүз кузгатып, "Мәгариф турында"гы законына төзәтмәләр әзерләде. Анда укучының педагогка һөҗүм итүе өчен 5 мең сум штраф һәм мәгариф хезмәткәрләренә карата физик көч кулланган өчен җинаять эше кузгатып, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган иде. Депутатлар аһ-ваһ килде, ләкин төзәтмәләр кабул ителмәде. Аның каравы, тотнаксыз балаларның ата-аналары укытучыларга каршы баш күтәрде. "Балаларны яратырга кирәк, ул чакта сезне беркем дә кыйнамас", "Педагогларны ихтирам итмәү аларның үзләренең эшли белмәүләреннән", "Әгәр мондый закон кабул ителсә, бөтен укытучылар әләкчегә әйләнәчәк", – бу алар тарафыннан белдерелгән ризасызлыкның кечкенә өлеше генә. Бу хәлнең килеп чыгу сәбәбен әллә каян эзлисе түгел. Белем, кешелеклелек һәм акыл бирергә тиешле профессия "хезмәт күрсәтү"гә әйләнгән. Ә хезмәтчеләр белән бездә сүз кыска!

Быел Россиядә педагоглар елы дип игълан ителде. Бу вакыйгага багышланган рәсми чаралар үткәрүдән башка, күптәннән үз сәгатен көткән иске мәсьәлә дә хәл ителер дип өметләнәсе килә. Һәрхәлдә, укытучыларның махсус статусы закон тарафыннан беркетеләчәк дип вәгъдә итәләр. Билгеле булганча, кайбер, хәтта иң талантлы педагог та өйрәтә алмаган нәрсәләргә бик үтемле итеп тормыш үзе өйрәтә, ә аеруча өметсез очракларда – җинаять кодексы.

Людмила САФИУЛЛИНА



– Улымның тәртибе турында сөйләшергә чакырткан идегезме?

Ринат АБЗАЛОВ

Андрей ДЁМИН



Михаил ЛАРИЧЕВ



Игорь КИЙКО





• • •

– Шеф, сезгә шалтыратуымның сәбәбе шул: мин бүген эшкә килә алмыйм – машинам ватылды.

– Автобуста кил, алай булгач...

– Автобусым юк бит минем...

• • •

– Шулхәтле чибәр син! Кемнең бәхетенәдер инде...

– Бәлки синең бәхеткәдер?

– Нигә әле менә минекенә?..

• • •

– Кая җыендың?

– Оптикага – күзлеккә...

– Ә аннан соң?

– Аннан соң күз күрер.

• • •

Агач утыртырга – ир. Малай тәрбияләргә – ир. Йорт салырга – ир. Ә шуларны ирләрчә билгеләп үтсә – исерек дуңгыз...

• • •

– Хатыным белән мөнәсәбәтләребез шулхәтле яхшы, чөнки барлык уй-фикерләребез туры килә. Мин балык тотарга яратам, ә ул минем балык тотарга китүемне ярата.

• • •

Сездә хатын-кыз оеклары бармы?

– Бар.

– Күрсәтегез әле

– Ниндие кирәк: хатыныгыз өченме, әллә яхшырагымы?

• • •

Хәрби хезмәткә чакырылучы военкоматта табибка керә. "Утырыгыз!" – ди табиб. Ул утыра. Табиб: "Яраклы", – дип әйтә.

Чакырылучы:

– Ничек, сез бит тикшермәдегез дә әле?

– Команданы ишеттеңме – ишеттең, урындыкны күрдеңме – күрдең, димәк, күрү сәләтең әйбәт, "Яраклы!" дигән команданы үтәргә акылың да җитте.

• • •

– Син кем?

– Мин – терминалның логистика супервайзеры!

– Төяүчеме әллә?

– Әйе.

Абау!

ӘКИЯТНЕ – ТОРМЫШКА!

Бөҗәкләр белән туклану ерактагы экзотик урыннарда яшәүчеләргә генә хас гадәт булудан туктый бугай. Күптән түгел Евросоюз азык-төлек исемлегенә өй чикерткәсен кертүне хуплады. Бу хәбәр Татарстанга да килеп җитте. Цифрлы үсеш министры Айрат Хәйруллин якташларына "микротерлекчелек" тармагы булдыру турында уйлап карарга тәкъдим ясады: имештер, бу арзан, туклыклы һәм экологик яктан да зыянсыз икән. Берәүләр бу гадәти булмаган тәкъдим өстендә баш ваткан арада, икенчеләр эчә торган суны сатып алуның да күптән түгел генә әкият итеп кабул ителгәнен искә алдылар.

КАЯ КИТӘЛӘР?

Татарстан Югары судында гаҗәеп факт билгеле булды. Республикада хөкем системасында кадрлар җитми икән. Бер ел эчендә мировой судьялар аппаратыннан 250 хезмәткәр киткән, бу – аларның гомуми санынннан 36 процент дигән сүз. Хөкемдарларның гына түгел, аларның ярдәмчеләренең дә саны сизелерлек кимегән. Хәзерге вакытта 101 судья вакансиясе ачык. Хөкем кадрларының кая китүе турында, гадәттәгечә, бер сүз дә әйтелми. .

ИНВАЛИДЛАР КОМАНДАСЫ


Түбән Камада ике нәфис хатын бернечә дистә кешене инвалид иткәннәр. Медик-социаль экспертиза бюросы җитәкчесе һәм шәфкать туташы "акчалата бүләк" өчен 60 кешегә 3 нче группа инвалид таныклыгы тоттырганнар. Бу "хезмәт" өчен табибларның кесәсенә 3,5 миллион сум кучеп утырган. Ришвәтче хатыннар кылган кыек эшләрен таныганнар һәм хокук органнары белән хезмәттәшлек итәргә ризалык биргәннәр. Ялган инвалидлар командасын да җәза көтә.

КРЕДИТКА САБАК

Казанда гүзәллек өлкәсендә эшләүче белгечләр аферист эш бирүчеләр тырнагына эләккәннәр. "Blackmight" студиясенә визажистлар кабул итү турындагы белдерү күпләрне кызыксындырган. Танышу әңгәмәсе вакытында эш эзләүчеләргә хезмәт урыны һәм түләүсез уку тәкъдим иткәннәр. Кызлар хезмәт килешенүенә имза куйганнар, әмма уку... кредитка булып чыккан. Бу кармакка утыздан артык туташ капкан. Бәлки, бу вакыйга яшь белгечләрне башта кәгазьне укып чыгарга, ә аннары гына астына имза куярга өйрәтер?..



Николай ВОРОНЦОВ



Валентин ДРУЖИНИН





Евгений ОБУХОВ

ТЫНЫЧ ТОРМЫШ

Хәзер бездәге караклык коточкыч! Берзаман йортыбызның активистлары бергә җыелдык та аның белән көрәшбашларга булдык. Карак ул кайда керә? Кайдадыр аны кызыксындырган әйбер бар, димәк. Элек спутник антенналары буенча табалар иде: әгәр тышкы стенасында "тәлинкә"се бар икән, монда бай гаилә яши. Бүген инде моның белән беркемне дә гаҗәпләндереп булмый. Антеннасы булмаса да, бу кеше бай йә ярлы түгел, ә акыллы дигән сүз...

Ә менә йортта консьержка булу – бөтенләй башка эш. Бездә әлеге җыелышка кадәр һәр подъездда берәр әбекәй утыра иде. Кайчагында хәтта кайберәүләрне кертмиләр дә иде. Бу бит тычкан-күсегә май кебек: әгәр саклыйлар икән, димәк алырдай әйбер бар! Тышкы ишекләргә куелган кодлы йозаклар да шулай ук. Караклар бит ул кодларны яттан белә – ә бу урлау теләгеН көчәйтә генә! Кыскасы, тавыш бирдек тә, әбекәйләрне өйләренә озаттык. Домофоннар өчен акча җыюны да туктаттык, чыбыкларын өзеп ташладык.

Өстәвенә, подъездларыбыз да матур һәм пәхтә иде. Үзләренә чакырып торалар бит! Ремонт ясатырга гастарбайтерларны чакырдык. Ремонттан соң карарлык түгел – хәерчеләр алачыгы диярсең! Фатир ишекләренә зыян салдылар – кайда кистеләр, кайда ярдылар, кайда көйдерделәр... Малайларга беренче катның тәрәзәләрен рәсемнәр белән бизәргә, ишегалдындагы фонарьларны ватып чыгарга куштык. Йортта яшәүчеләргә чүпне контейнерларга илтмәскә куштык – ишек каршында тротуарга гына бушатсыннар.

Бу үзгәрешләргә карап – шатланып куйдык. Йорт түгел, чын җен оясы! Берниндиг каракның да монда кереп вакыт әрәм итеп йөрү башына да килмәс! Ел буена берәү кереп чыккан, анысы да бер пенсионер Егорычның фатирына юлыккан. Карап чыккан – алыр нәрсә юк, хуҗа абзыйга өстәлендә мең сум калдырып чыгып киткән.

Күңелне тырнап торганы – безнең рәхәт һәм тыныч тормышыбызны юкка чыгарырга маташалар. Әле менә күптән түгел узып барганда безнең йортны шәһәр хакимияте кешеләре күреп алган, һәм шунда аны яңа йортка күчерү программасына керткән. Ә андагы яңа йортлар шундый матурлар – бер генә карак та битараф узып китмәс. Димәк, тиздән безне өр-яңа фатирларга күчерәчәкләр булып чыга? Моның нәтиҗәләре озак көттермәс... Менә анысы бәланең дә бәласе!



Авто! СТОП!

"БАЛТА ОСТАСЫ"

Әгерҗе районында бер исерек йөртүче, "Гранта"сында барган чакта, юл читендә видеокамера күреп алган. Моңа кадәр хөкем ителгән Чаллы егете бу приборны нигәдер ошатмаган, һәм ул, кулына балта алып, аны чәлпәрәмә китергән. Ярсыган машина йөртүчене юл хәрәкәте иминлеге хезмәткәре тынычландырырга тырышып караган, ләкин исерек ир аңа да яный башлаган. Нәтиҗәдә, балта болгап йөргән җәнҗалчыга 700 мең сум матди зыянны капларга һәм шартлы рәвештә өч ел ирегеннән мәхрүм булып яшәргә туры киләчәк.

ДҮРТ КӨПЧӘКЛЕ КОНТРАБАНДА

Татарстанда яшәүче берәү Абхазиядән "Мерседес 500 Е" автомобиле алып кайткан. Адлер таможнясында ул машинаны пассажирлар йөртү өчен халыкара транспорт чарасы сыйфатында алып кайта дип белдергән һәм ялган документлар күрсәткән. Аннан соң аның номерларын Абхазиянекеннән Казакъстанныкына алыштырган. Әмма таможенниклар бу хәлнең очына чыкканнар, кәгазьләрнең ялган булуын ачыклаганнар һәм җыелып килгән таможня түләүләренең суммасын исәпләп чыгарганнар. Ул 2,5 миллион сум тәшкил иткән. Хәзер эше пешмәгән контрабандистка башта тикшерүче, ә аннан соң судья сорауларына җавап бирергә туры киләчәк.

ТӨНГЕ ЮЛЧЫ

Чаллыда яшәүче берәү төнлә полициягә автомойка парковкасында калдырылган машинасының юкка чыгуы турында хәбәр иткән. Тиздән, аны исән хәлдә табып, хуҗасына кайтарганнар. Кеше автомобильләрендә йөрергә яратучыны да тоткарлаганнар. Ул исерек хәлдә танышларыннан кайтып барганда үзенең адашканын аңлап алган. Эшләп торучы автомобильне күреп, егет рульгә утырган һәм таныш урыннарына кайтып җиткән. Хәзер шәһәрдән чыгу мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән төнге юлчы өендә язмышының хәл итүен көтә.

АЛАРНЫ ИНТЕРПОЛ ЭЗЛИ

Молдавиягә эш визиты белән Румыниядән дәүләт делегациясе килеп төшкән. Автомобильләрне тикшергән чакта, Молдавиянең чик сакчылары аның берсенең Интерпол базасында Италиядән урланган булып исәпләнүен ачыклаганнар. 2010 елдан башлап машина берничә тапкыр хуҗасын алыштырган, ә 2020 елда хезмәт машинасы буларак калкып чыккан. Румыния делегациясе вәкилләре белдерүенчә, автомобильләрен полиция эзләве турында алар берни дә белмәгәннәр.



• • •

– Кичә күршенең пычранып беткән машинасына «Ю мине» дип язган идем. Бүген карыйм, машина шулай ук пычрак, ә мин язган язуның астына «Кил – юам!» дип язылган.

• • •

Техник хезмәт күрсәтү станциясендә:

– Нишләптер машинам йөрми башлады әле.

– Ә сез, туташ, шиналарыгызда һаваны күптән алыштырдыгызмы?

– Ә нәрсә, аны алыштырырга кирәкмени?

– Әлбәттә! Менә безгә кичә генә балоннарда импортный саф һава китерттеләр...



Александр ШУЛЬПИНОВ

Ял итүчеләрне моңсулык баскан. Инде барысы да бер-берсе белән таныш. Гаилә хәлләрен дә белешеп бетергәннәр, инде гайбәт сөйләү темалары да кабатлана башлаган.

Башкаладан килергә тиешле ирле-хатынлы кешеләрнең озакламый килеп җитүләре дә мәгълүм. Профессор икән – филолог, берничә монография авторы, иң алдынгы югары уку йорты педагогы. Ял йортының хезмәткәрләре генә түгел, моңсуланып йөрүче ханымнарга да җан керде.

Наталья БАХТИНА

ПРОФЕССОР



Менә боларны алып килгән такси санаторий капкасына килеп туктады. Зур гына гәүдәле, ыспай, шактый өлкән яшьтәге ир, бик затлы кәчтүмнән һәм кара күзлектән – менә дигән профессор. Аның кырыенда чыпчык кадәр генә хатыны бөтерелә. Гади генә күлмәктән, чәчләре дә тузгыган килеш – койрык сыман җыелып кына куелган.

Алла – бик мулдан кершән яккан, 50 яшьләр тирәсендәге чибәркәй, башкалар янында шулайрак чагыла – ушлана ук башлады.

– Җитәр, ике яшелчә ларёгы хуҗабикәсе булудан туктарга кирәк! – дип әйтеп куйды. – Исемем Алла булмасын, профессорны үземнеке итмәсәм. Башкалада яшисем килә! – дип кырт кисте ул.

– Ул бит хатыны белән килгән! – диделәр аңа сердәшләре.

– Барысы да мин дигәнчә була! Хатыны белән эшне рәтлим, проблема түгел... – дип, күкрәген кагып куйды Алла.

Болар артыннан бөтен санаторий күзәтә башлады – нишләрләр икән... Профессор көен көйләтергә бик җайлы кеше булып чыкты. Ә хатыны аның кан басымын күзәтү белән генә борчылды. Алла белән ир бию мәйданында типтергәндә, хатыны аның җылырак киенеп йөрүен кайгыртты, чөнки елга кырыенда салкынчарак иде кичләрен.

Атна ахырында Алла профессор хатынын үзенең киләчәктәге планнары белән таныштырды. Ә хатыны исә аңа аң-белем биреп, иренең сәламәтлеге турында сөйләде – ә анысы әллә ни мактанырлык түгел икән. Гомере буе газапланып яши икән сөеклесе белән. Ә Алла үзенекендә нык торды. Ул инде үзен челтәрле кара эшләпәдән тол хатын итеп күз алдына китерә.

– Юк, юк, без бер-беребез өчен яратылган, мин профессорны гомере буе күрмәгән ихтирамга күмәм... – дип кабатлый ул бертуктаусыз...

– Туктагыз әле, профессор ул түгел, мин – профессор, – дип, көч-хәл белән әйтеп куйды ханым... – Ул, гафу итегез, минем ирем...

– Сез нәрсә минем башны бутыйсыз?! – дип кабынды Алла. – Әле профессор да икәнсез! Сезнең пенсионерыгыз өчен бөтен ялымны әрәм иттем...



Алексей МАМАЕВ

ЫШАНСАҢ, ЫШАН...

ХӘРБИ ТАПКЫРЛЫК

Бу тарихны миңа бер танышым сөйләде. Ул армиядә инде "дед" булып хезмәт иткән чакта аларның частена Мәскәүдән бер өлкән лейтенантны җибәрәләр. Бу офицер бик коры һәм таләпчән була, һәм Устав буенча гына хезмәт итәргә тырыша. Ә монда, Ерак Көнчыгышның ерак почмагында дисциплина ягы бераз аксый, һәм яңа тәртипләрне солдатлар теләмичә кабул итә. Берзаман, гомергә булмаганны, ротаны кичке прогулкага алып чыгалар. Моны "дед"лар аеруча кискен кичерә — бу бит алар өчен кимсетүгә тиң!

Бу хәлдән чыгу юлы бик тиз табыла. Рота йөргән мәйданчыкның янәшәсендә офицерлар яши торган йорт урнашкан була. Фатирларның тәрәзәләре, шулай ук полк командирыныкы да плац ягына карап тора. Солдатлар бераз пышылдашып ала һәм марш белән киткәч, шундук бөтен шәһәрчекне аякка бастырырлык җыр яңгырап китә. Ә вакыт кичке ун, балаларны йокларга яткыра торган вакыт...

Полк командиры, тәрәзәсен ачып, бар булган тел байлыгын дөньяга сибә. Өлкән лейтенант шуннан соң безне кичке маршларга алып чыкмый башлады. Хәрби тапкырлык менә шундый була ул...

ТӨГӘЛ ҖАВАП

Кибеттә сок сатып алам, тышына «Аксым кушылган алма согы» дип язылган. Сатучыдан сорыйм:

– Ә аксымы соянныкыдыр инде?


Ул елмаеп җавап бирә:

– Юк, алмалары кортлы булгандыр аның!

ПАРОЛЬ

Ә бу хәлне бер фирмада система администраторы булып эшләүче иптәшем сөйләде. Берзаман декрет ялыннан соң бер хезмәткәр хатын эшкә чыга. Ә эчке программаның паролен оныткан була. Аны махсус программа ярдәмендә ачарга тырышып карыйлар, ләкин нәтиҗә бер үк: "Пароль кертегез". Бу программа куелган максатка ирешмәде дип уйлап, иптәшем башкасын тоташтырып карый. Нәтиҗә һаман шул ук: "Пароль кертегез". Бу эш өстендә ике сәгать чамасы утырганнан соң, "берни дә барып чыкмады", дип әйтергә җыенганда, онытучы хатын шатланып кычкырып җибәрә: "Ура! Исемә төште!" Пароле "Пароль кертегез" булган икән.

Виталий ВАВУЛИН



КАЙДА ЙӨРИ ЕГЕТЛӘР?

Рашат НИЗАМИ

Яшь кызларның кулларында
Көмеш балдак, беләзек.
Кемнең генә килмәс икән
Сөясе, сөеләсе?

Кушымта:

Заманыбызның кызлары –
Эшмәкәрләр, чибәрләр!
Сөяр өчен яр табылмый,
Кайда йөри егетләр?

Әй, дускаем, тыйнак булып
Югалтмаммы бәхетне?
Егетнең күзе төшсә, һай,
Булыр идем бәхетле!

Кушымта.

Зирәк егет очрый икән,
Аңа ничек дәшәргә?
Безгә насыйп дигәннәре
Бәлкидер, янәшәдә!..


Кушымта:

Заманыбызның кызлары
Эшмәкәрләр, чибәрләр!
Сөяр өчен яр табылмый,
Кайда йөри егетләр?
Сөям дисәң, яр табылмый,
Кайда соң сез, егетләр?





Валерий ТАРАСЕНКО



Александр ШУЛЬПИНОВ



Виктор ФЁДОРОВ



ИРЕКЛЕ РӘВЕШТӘ

Россиянең Үзәк банкы хәбәр иткәнчә, 2022 елда коммерция банклары россиялеләргә урланган акчаларының нибары 4,8 процентын гына кире кайтарганнар. Мондый түбән нәтиҗәне кибер җинаятьчеләр тәэсирендә кеше үзе мәгълүматны үзе биргән яки үз теләге белән акча күчергәнлеге белән аңлатканнар. Гамәлдәге законнар нигезендә, акча күчерү ирекле рәвештә ясалган булса, мошенниклар корбанына банк акчаны кире кайтарырга тиеш түгел.

ПРОФЕССОР – ЛОПУХ

РГГУ студенты Александр Ждан нейрон челтәр ярдәмендә бер көн эчендә диплом эшен язган. Чатботка кулланмаларны һәм соңгы эш үрнәген кертеп, ул үзенчәлеге 82% булган текст алган. Яклау белән проблемалар булмаган. Студентның зирәклеге югары белем системасын җимерергә мөмкин. Соңгы эшне теоретик презентация формасында түгел, ә шәхси фәнни тикшеренүләр һәм практик тәҗрибәләр белән эшләргә тәкъдимнәр бар, хәтта гуманитарийлар өчен дә.

БЕР ТИЕНЛЕК ЯРДӘМ

Төмән өлкәсенең Ишим шәһәрендә яшәүче коммуналь хезмәтләр өчен ташламага документлар җыйган һәм дәүләттән ярдәм алган ... бер тиен. Бу әле аның коммуналь түләүләре 10 мең сумга кадәр җиткәнгә карамастан. Шәһәр хакимияте дәүләт хезмәтләре порталында субсидия бирү карары формасының камилсезлегеннән зарланган һәм финанс ярдәмнең яңадан исәпләнәчәген хәбәр иткән.

КРЕДИТ ДИВЕРСИЯСЕ

Чираттагы «банк куркынычсызлыгы хезмәткәре» Мәскәү өлкәсенең Поречье авылында яшәүчегә шалтыраткан. Ул бу ирнең акчаларын саклап калу өчен, 1,35 миллион сум кредит алырга һәм күрсәтелгән счетка күчерергә күндергән. Аннары «банк хезмәткәре» клиентка «Молотов коктейле» ясарга өйрәткән һәм аны якындагы банк филиалына атарга киңәш иткән. Бу ир барлык күрсәтмәләрне төгәл үтәгән. Хәзер «диверсант»ның адекватлыгы судта ачыкланачак.

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Бәйрәм бүләге

– Кеше ирләре шикелле кайчан гына ярдәм итә башларсың икән син? – дигән сүз белән башлый һәр ял көнен хатыны.

– Башка ирләр аракы эчә, ә мин – эчмим. Ни җитми инде сиңа? – дип җавап кайтарды ире.

– Мин эчү турында сүз кузгатмыйм бит әле. Кара, өйдә күпме эш. Кайчаннан бирле киштәләрне элеп куярга сорыйм. Ә син һаман телевизор каршында. Кыш үтә, паласларны да алып чыкмыйсың чистартырга.

– Нәрсәгә ул паласны алып чыгарга пылесос булганда? Хәзер кеше урамга чыгарып палас селкеми.

– Ялкау алар. Фатирларында синең шикелле тик яталар. Аннан, шуны да әйтәсем килә: беркая бармыйбыз.

– Җанашым, атна буе эштә бит мин. Ардыра. Ял итәсе килә бераз.

– Әнә, күршеләр атна саен йә киногa, йә театрга йөриләр. Ә без – өй ияләре…

Шулай яши-яши тагын берничә ял көне үтеп китте.

Көннәрнең берендә ире эштән кайтуга хатынын сөендерергә уйлады:

– Кадерлем, озакламый хатын-кызлар бәйрәме җитә. Мин сиңа ул көнгә бүләк ясарга булдым.

– Нинди бүләк? – дип, хатыны шатланып иренә карады.

– Күптән зарланасың беркая барган юк, дип, минә театрга билет алдым. Бәйрәмегез күңелле үтсен әле.


– Нинди театрга барабыз? – диде хатыны, сөенеп.

– Барабыз түгел – син барасың.

– Ничек инде? Берүзем бараммы? Алай булмый. Мин риза түгел.

– Сөеклем, син театрга барасың, ә мин өй эшләрен эшләп куям синең кайтышка: киштәне эләм, паласны селким. Кыскасы, син әйткән нәрсәнең барысын да эшлим. Ә син ял ит. Синең бәйрәм…

Хатыны килеште. Бәйрәм көнне бизәнеп-ясанып театрга китте. Кичен күтәренке кәеф белән өйгә кайтып керсә… палас шул килеш, киштәләр идәндә, телевизор гөр килеп сөйли, ә диванда… ире йоклап ята…



Василий АЛЕКСАНДРОВ

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Мөстәкыйль хатын ул – үзенә буйсынырга теләүчене таба алмаган хатын.

Гыйшык эшләрендә хатыннарның өч төре белән эш итәргә туры килә: өйләнә торган, ярата торган һәм тули торган. Әмма аның бер үк хатын булуы да мөмкин. Акчадан башлап, ир кеше гашыйк була, ә ахырында өйләнә.

Синнән хатыныңны тартып алган ирга эшләргә мөмкин булган иң зур этлек – аңа хатыныңны калдырып китү.

Иң нык яшәртә торган нәрсә – яшьлек хаталарыңа әйләнеп кайту.

Өйләнгән ирнең бәхәстә соңгы сүз әйтүнең бердәнбер мөмкинлеге – хатынына "син хаклы" дип әйтү.

Хатын-кыз ир кешене бөек эшләргә рухландыра һәм аларны башкаруда комачаулый.

ГҮЗӘЛЛӘРЕБЕЗДӘН – ШИГЪРИ МИЗГЕЛЛӘР

Илсөяр ИКСАНОВА

БӘРГӘЛӘНҮ

Йә күккә ашыр җанымны,
Йә җиргә төшер, Ходам!
Бер очып китәр күк булам,
Бер калыр төсле булам.
Күкләрдә – ябалдашларым,
Җирләрдә тамырларым.
Күкләрдә – сагынганнарым,
Өзелеп калырларым.
Җирләрдә
Бәргәләнә җан
Җир һәм Күк арасында.
Ике дөньяның сагышы
Бер йөрәк ярасында!

Нәҗибә САФИНА

• • •

Карап торсаң, болытлардан
Җил ни генә ясамый.
Бу куянны арсланнар,
Белмим, ничек ашамый?
Бүре белән сарык та,
Төлке белән тавык та,
Аю алдында – кеше, –
Бер-берсендә юк эше.
Күктә генә шулай ул,
Җирдә алай булмый шул.
Бер-берсен ашаганчы,
Күккә күтәреп күзләрен
Карасыннар иде, болыт
Яварга башлаганчы.
Һи, ява да башлады.
Анда да тик мизгеллек –
Дөньядагы тигезлек.

Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА

НИШЛИМ?..

Сине өзелеп сөюемне
Ничек аңлатыйм икән?
Йокыларыңнан уятып,
Таң булып атыйм микән?

Әллә шатлык яше булып
Күзләреңнән тамыйммы?
Сандугач булып сайрыйммы,
Гөлләр булып карыйммы?

Җырлар булып, моңнар булып
Күңелеңә тулыйммы?
Әллә үзем генә булып,
Гел яныңда торыйммы?

Сания ӘХМӘТҖАНОВА

УРТАЛЫК

Үкчәләре белән кәс-кәс чүкеп,
Бер кыз үтте тәрәз каршымнан.
Үзем күрмәсәм дә, чамаладым –
Ут чәчрәтте асфальт ташыннан.

Аякларын көч-хәл генә атлап,
Бер өлкәне чыккан иртәләп.
Таягы да үзе кебек салмак –
Бара җирне сыйпап-иркәләп.

Мин дә киим җәйге туфлиләрне...
Көзгегә күз салдым тукталып.
Таш та тишәм, таякка да иртә,
Җитезлегем – уйчан урталык.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

• • •

Йөгермәс тә идем, бәлки,
Еллар ашыктыра бик тә!
Җырламас та идем, бәлки,
Ярсу хисләр, дәрья судай, ташып китә.
Уйламас та идем, бәлки,
Билгесезлек күңелемне уттай өтә.
...Яшәмәс тә идем, бәлки,
Ак пәрдәле бу киләчәк мине көтә!
Мине көтә...

Лилия ФӘТТАХОВА

• • •

Ә мин көн дә
Бераз гына бүтән...
Бераз гына бүтән
уйлар уйлыйм,
Бераз гына бүтән
күлмәк киям...
Ялкын киткән
йөрәк белән бергә
Акыл чуалдырган
үем тетәм...
Йөрәк белән
уйлыйм бугай хәзер...
Бераз гына башкачарак кичем,
Бераз гына башкачарак иртәм...
Саксыз кыланганым өчен кичер –
Тик шул үем үзгәртмичә йөртәм...







Илдус ДИНДАРОВ

ГАЛИЯБАНУГА МИННӘН КАЛГАНЫ!

Мирхәйдәр Фәйзинең "Галиябану" драмасын куйганда борынгы кием-салымны гадәттәгечә халыктан җыялар авылда. Яман да кысмыр, саран Гандәлиф әбинең өенә дә сугылырга туры килә. Гозерләп керми хәлең юк, төп рольне башкаручы өчен балитәкле һәйбәт күлмәк бер аңарда гына сакланган, имеш. Гомере буе кеше-кара белән аралашмый гына, япа-ялгыз яшәүче, "тиәтер" дигән гөнаһ шомлыгы ике ятып бер төшенә дә кермәгән явыз карчык һич кенә дә ачык чырай күрсәтми шул "әртисләргә". Иске-москы әйбере бикләнгән сандыгына кунаклаган килеш "юк"тан гайре бүтәнне белми дә. "Әби җаным, Галиябану өчен бит ул!" – дип инәлгәч тә:

– Булмагае! Әүвәл үзем киеп туздырам әле асыл күлмәгемне, аннары калса Галиябануга калыр, – дип, авызыннан ут чәчеп утыра, ди.

ХӘЛЕНӘ КЕРҮ

Ул колхоз рәисен бүген дә сагынып сөйлиләр. Исеме чыгуга, көлеп тә куйгалыйлар. Яратып, үз итеп искә алырлык мәзәк хәлләре булгалаган икән шул мәрхүмнең.

Берсендә шулай өендә ялгыз гына "пирәшләп", үзе әйтмешли, "кан таратып" утыра икән бу. Көтмәгәндә телефоннан райкомга ашыгыч чакырталар моны. Киндердәй агарып каткан агаең. Соң, салган килеш "беренче" катына барулары... җәһәннәмгә эләгү белән бер.

"Бәлки, аракы исе сеңеп өлгермәгәндер", – дип, үзен-үзе тынычландырмакчы, юатмакчы пред. Туктале, кем беләндер киңәшеп, сынап карарга кирәк. Үч иткәндәй, хатыны да каядыр чыгып шылган. Урамда эт заты күренми. Җәйге чиллә, халык, кырылышып, печән хәстәрли. Бәхетенә, шулчак тыкрыктан алпан-тилпән килеп, ниндидер ир кәмәше пәйда була. Янына чакырып ала да, тегенең ике-өч көн су тимәгән кызыл танаулы битенә сулышын өрә: "Җәтрәк әйт, аракы исе килмиме?"

Соңыннан сөйләделәр: үзенең дә каты махмырдан изаланган мәле була әлеге мәңге айнымас агайның. Кайда инде болай чит кешедән истәм тою, нидер сизү? Килеп каптым предка, дип, шыр җибәрүе дә аңлашыла. Мәгәр: "Юк, юк, Фәлән Фәләнович, ул-бу сизелми, фәрештә сулышы кебек!" дип алдашып котыла. Бераздан, иркенәеп, шикләрен тараткан "перси" машинада Нурлатка китә...

ДӘЛИЛ

Ярты гасырдан артык колхоз башында, симерепнитеп, тәмам эштән чыккан Фәтхи аганы яңадан урынында калдырыргамы-юкмы дип бәхәсләшәләр икән хисап-сайлау җыелышында. Күбесе, аяк терәп, каршы тора. Картайды, артыннан ком коела, корсагын май басты, череп баеды, фәлән-фәсхет. Шулчакны Аю Хафизы сикереп торган да:

– Әйдә, эшләсен лә үзе кәкрәеп катканчы. Яңасын тагын илле елга муеныбызга атландырыйкмыни?! Пакрайне мере, бусы инде әллә ни озакка сузмас шикелле, – дип акырган, тегенең какшаган сәламәтлеген дә күздә тотып.



Светлана ФАТТАХОВА, Чаян, 1986 ел.



Виталий ФЕОКТИСТОВ, Чаян, 2003 ел.



• • •

– Минем принтерны кара әле.
– Нәрсә булган аңа?
– Сайтка керәм, мәзәкләр укыйм – кызык, бастырып чыгарам – бөтенләй кызык түгел.

• • •

Судья:
– Ни өчен санаторийдә дәваланып ятуыгызны дәүләт бюджетыннан түләдегез?
Түрә:
– Барысына да минем табибым гаепле, ул миңа дәвалану өчен халык средстволарын кулланырга кушты.

• • •

Трамвайда.
– Киләсе тукталышта төшәсезме?
– Юк.
– Алайса, әйдәгез алмашыйк.
– Әйдәгез. Ә нәрсәгез бар соң сезнең?

• • •

Зоопаркта:
– Әни, миңа фил сатып алыйк әле!
– Нәрсә белән туйдырырбыз соң аны?
– Берни белән дә түгел. Әнә бит, "Филне ашату катгый тыела!" – дип язып куелган!

• • •

– Котлыйм! Җирнең яссы икәнлеге турындагы фильмыгыз премиягә лаек булган!
– Нинди премия?
– "Алтын глобус".

• • •

– Әйдә, тартуны ташлыйбыз!
– Нигә?
– Ул бит айга нихәтле акчаны янга калдыра!
– Әйдә, алай булгач, эчүне дә ташлыйбыз!
– Ә безгә шулхәтле акча нигә соң?

• • •

Иң бәхетле кеше Робинзон Крузо булган. Үзенең шәхси утравы, чип-чиста эчә торган суы, төрле ризык-нигъмәтләр белән тулы урман, хайваннар, берүзенә бер диңгез... Экологик чиста ашамлыклар гына ашап торган. Аның мөлкәтенә берәү дә кул сузмаган. Салым түләмәгән. Берәү дә җанын кимермәгән. Акча белән дә проблемасы булмаган. Үз законы белән яшәгән. Менә бу бәхет аңа 30 ел буена җиткән!

• • •

Шунысы мәгълүм: үзенеке булган керфекле һәм тырнаклылар – алар ярлы кешеләр!



Виктор ФЁДОРОВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Александр АЛЁШИН



ТИЗӘККӘ БАТЫРАЛАР...

Кадерле "Чаян"! Инде ничәмә-ничә еллар Якут илендәге бер скульптор авылдашларын үзенең тирестән эшләнгән эшләнмәләре белән куандырып тора. Ул, шактый күңелгә ятышсыз чималдан ел символлары ясап, авыл үзәгендә урнаштыра. Күптән түгел безнең авылдан ерак түгел урында шундыйрак әйберләрне ясардай материал өемнәре барлыкка килә башлады. Каян чыккан хәл бу?.. Әллә ни аптырашлык мәсьәлә түгел икән – янәшәдәге күркә фермасы, үз тирәягында чисталык урнаштыру максаты белән, бөтен җыелган чүп-чарны, күркә тизәкләрен авыл кырыендагы басуга түгә башлаган. Шуннан сиксәнгә якын зур-зур өемнәр хасил булган. Бу урын калку урында икәнен исәпкә алганда, димәк, язгы ташкыннар башлангач, барлык тизәк эремәсе безнең урамнарга, коеларга, инешләргә, чишмәләргә төшәчәк. Инде матур гына күлебезгә дә зур зыян киләчәк – без бит аны үзебезнең акчага һәрдаим чистартып тора идек. Район җитәкчелеге дә, ферма түрәләре дә монда бернинди фаҗига күрмиләр. Әле авыл халкына бушлай черемә агызабыз, дип мактана да торганнардыр...

Маёвка авылында яшәүчеләр

Яшел Үзән районы

КИРӘКСЕЗ БАЛКОН КАШЛАРЫ

Хөрмәтле редакция! 1936 елны төзелгән йортыбызга 15 ел элек капиталь ремонт ясаганнар иде. Яңартып эшләнгән бинабызның өске каттагы балконнарына түбә кую күңелләргә хуш килде. Әмма тормыш үзгәрә тора, шуның белән бергә нормалар һәм кагыйдәләр дә. Кашлы балконнар йортның гомуми мөлкәте булудан да туктады, һәм без – яшәүчеләргә дә куркыныч тудыручы әйбергә әйләнде. Бәлки шулай кирәктер, ләкин идарәче компания әлеге өске каплагыч түбәләр монда яшәүчеләрнең үзләре тарафыннан сүтелергә тиеш дигән карарга килгән. Бу мәсьәләне суд аша тормышка ашырырга маташалар. Төп аргументлары – сугышка хәтле документларда балконнарда бернинди дә түбә-кашлар куелырга тиеш булмаган. Ләкин анда бит әле газ плитәләре дә, домофоннар да проектта каралмаган. Монысын да безнең өскә өеп, яшәүчеләр акчасына нормага китерерләр микәнни? Кагыйдәләрне гел үзгәртеп торучылардан бераүнең дә ота алганы юк бит әле...

Лядов урамының 10 нчы йортында яшәүчеләр

КАЗАН



КӨЛКЕ КАМЕРАСЫ



Александр АЛЁШИН



Вячеслав ШИЛОВ



Фәнис Яруллин 1938 елның 9 февралендә Татарстан АССРның Баулы районы Кызылъяр авылында игенче гаиләсендә туган. Баулы урта мәктәбендә 8 сыйныф тәмамлый. 1957 елда Совет Армиясе сафларына чакырыла. Армиядә һава укчы радистлар мәктәбендә укый, спорт белән мавыга. Спорт күнегүләренең берсендә турниктан егылып, имгәнеп, гомерлеккә йөри алмас халдә кала.

Озак еллар урын өстендә яки хастаханәләрдә дәваланып ятуына карамастан, Фәнис Яруллин бөтен тырышлыгын, рухи көчен үзенең белем дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлтә: 1963 елда экстерн тәртибендә урта мәктәп программасы буенча имтихан тота, 1970 елда исә, читтән торып укып, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Шул елларда шигырьләр, хикәяләр язарга керешә.

Фәнис Яруллин – ике дистәгә якын шигырь һәм проза китаплары авторы. 1978 елда «Аерылмас дустым» һәм «Сулыш» шигъри җыентыклары өчен автор Татарстанның Муса Җәлил исемендәге комсомол премиясенә лаек булды. Аның «Әнә килә автомобиль» комедиясе Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсенә менеп, берничә сезон рәттән өзлексез уйналып килде һәм тамашачыларда уңыш казанды.

Әдип – Татарстанның халык шагыйре, М. Җәлил премиясе лауреаты.

Фәнис Яруллин 2011 елның 8 декабрендә Казан шәһәрендә вафат була.

МӘХӘББӘТ – АРТЫК МӘШӘКАТЬ

Мәхәббәт – артык мәшәкать,
Мин куркам мәшәкатьтән.
Кем соң файда күргән әле
Сөюдән, мәхәббәттән?!

Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә,
Алар янган, ни калган?
Берни дә калмаган икән,
Димәк, барсы да ялган.

Юк, юк, мәхәббәт турында
Сүз кузгатмагыз бүтән.
Әйтерләр: бу бичара да
Безнең күк юләр икән.

МОННАН СОҢ БЕРКЕМНЕ СӨЙМӘМ

Моннан соң беркемне сөймәм,
Дигән идең бит, йөрәк?
Тагын кем шырпы ташлады,
Нигә янасың дөрләп?

Инде бүтән һичбер кызга
Карамам дигән күзләр
Айкый төнге йолдызларны,
Синең карашың эзләп.

Беркемгә татлы сүз әйтмәм,
Дип антлар эчкән телем
Туктаусыз синең исемне
Кабатлап тора бүген.

ЙОЛДЫЗЛАР ТЕЗЕП ҮТӘРБЕЗ

Кояш кереп оялады
Тып-тын йөрәгемә.
Балкышы шаян нур булып
Чыкты йөзләремә.

Балкыйм, янам, дулкынланам
Яшьлегемә кайттым.
Алып менеп китте күккә
Ак канатлы атым.

Монда дөнья гел башкача,
Хисләр агымы кайнар.
Тамырларда дөрли-дөрли
Ага уттай каннар.

Җир белән күкләр кушылды,
Утлар белән сулар.
Йөрәккә кергән кояшта
Янды бер үк уйлар.

Шушы бәхетнең гомерен
Озынайтырга теләп,
Ак канатлы ат өстендә
Йөрдем галәм иңләп.

Бу мизгелләр уйда мең кат
Кабатланыр әле:
Бөркет яки аккош булып
Канатланыр әле.

Һәм күтәрер шул канатлар
Безне югарыга.
Йолдызлар тезеп үтәрбез
Сөю юлларына.

ТЕЛЕФОННЫЙ МӘХӘББӘТ

Безнең мәхәббәт бик кызык –
Телефонный мәхәббәт.
Сөйләшәбез, гөрләшәбез,
Әй җайлы соң, әй рәхәт.
Очрашырга йөрисе юк,
Ятасың өйдә генә.
Кәчтүм-чалбарың да тузмый,
Тора гел чөйдә генә.
Чәчәкләр сатып алмыйсың
Әз-мәз хезмәт хакыңа.
Ә бит пучтәк чәчәкнең дә
Бәясе тиң алтынга.
Ачуланышкан чак булса,
Йөрмисең һич үпкәләп:
«Телефон өзелде», – дисең,
Тавыш китсә күпкәрәк.
Әй шәп инде бу телефон
Заманасына күрә –
Сине шәп егет иттерә,
Ямьсезлегең яшерә.
Хисләрне яшерен түгәбез,
Серле безнең мәхәббәт.
Шулай сер саклый белгәнгә
Телефонга мең рәхмәт.

ЭШЕН ТАПТЫ

Мөнир мөдир булып алды
Тавыклар фермасында.
Ни әйтсәң дә, начальник бит, –
Китерде формасын да.

Креслосын ул кертеп куйды
Тавыклар кетәгенә,
Җитәкчелек итә-итә,
Утыра читтә генә.

Кешеләрнең киңәшләрен
Тыңлап та тормады ул.
– Тавыкны күкәй өйрәтми, –
Дип кенә җырлады ул.

Кызлар аны кызык итте,
Кузгаттылар аз гына;
Йомырка кертеп өйделәр
Утыргычы астына.

– Сине мөдир дип йөргәнбез,
Гафу ит, зинһар, – диләр, –
Син тавык икән ләбаса,
Чебешләр чыгар, – диләр.

Дамир БӘДРИЕВ

ТА-ТА-Р-АКАН

Кеше олыгая барган саен, акыл туплый: язучыга, шагыйрьгә, галимгә әверелә. Ул тормышка, инде мәгълүм тәгълимат-кагыйдәләргә яңача карый.

Яшьләр андыйларны "җиңеләйгән" яки "түбәсе авышкан" дип бәяли, әлбәттә. Гомер искиткеч тиз уза, аларның да "тузга язмаган" ачышлар ясап йөриселәре алда әле. Алтмыштан узгач, миңа да фәндәге төрле "ялгышлар" күренә башлады, җәмагать. Мәсәлән, хөрмәтле Дарвин әфәнде, "кеше маймылдан барлыкка килгән", дип, һич кенә дә дөрес әйтмәгән ул. Минемчә, татарлар тараканнан яралган. "Юк, без – ак бүре балалары", – дип каршы төшәр кайбер милләттәшләр. Килешәм, борынгы заманнарда кыю, ирек яратучы бүре булганбыздыр. Ләкин нык кырылырга керешкәч, тараканнарга әверелеп, ярыкларга кереп качканбыз. Җанисәп алучылардан куркып, "татар" дип әйтәсе урынга "та-та-р-акан" дип, тотлыгып, пышылдаганбыз.

Маймылларны "теләсә ничек көн күрегез" дип, үз язмышларына калдырып карагыз әле сез. Күптән җир йөзеннән юкка чыгарлар иде инде. Тараканнар бер тәгам ризыксыз айлар дәвамында яши ала, ди. Әле үрчи!

Татарларның тараканнан яралганлыгы турындагы ачышымны Гиннесс китабына тәкъдим итәргә ниятләп торам. Премиянең бер өлешен язучы Мөхәммәт Мәһдиевкә багышларга туры килер, кәнишне. Ул студентлар белән "ата кара тараканның кан әйләнешен өйрәнеп", шушы төшенчәне купкә алданрак тикшерә башлаган кеше иде, бахыр. Тик "татарлар-таракан" дип расларга гына өлгермәде.

Фән белән тирәнтен кызыксынган иптәшләр минем белән һаман да килешмәскә тырышыр. Татарлар алар сарыктан, тавыктан, дуңгыздан, эттән, төлкедән, еланнан һәм тагын әллә нинди җәнлек-кошлардан яралган, дияр. Юк, бу тараканның төре, токымы һәм холык сыйфаты рәвешләре генә. Мәсәлән, без миңгерәүләргә – "таракан сарыгы", усалларга – "таракан эте", зәһәрләргә – "таракан еланы", хәйләкәрләргә – "таракан төлкесе" һәм башка чагыштырулар китерә алабыз.

Һиндстандагы халыкларда филләргә, күселәргә, сыерларга табыну – изгеләштерү галәмәте бар. Балаларыгызны "тараканнар – алар татарлар" дип тәрбияләп үстерә күрмәгез берүк. Таракан күзегезгә чалынса, сыртына кундырыгыз. Бәлки, тараканнар: "Ярыкка посып яшәү туйдырды", – дип, кабаттан ак бүреләргә әверелер.

Мәхмүт ХӨСӘЕН

БУЙ БӘЛАСЕ

Акылым да бар, төс тә әйбәт,
Әллә нишләп тик буй кечкенә,
Кызык хәлләр кайчак булып ала
Шуның аркасында еш кына.
Беркөн менә, кулга акча төшкәч,
Ирешергә уйлап морадка,
Билетка дип театрга барам,
Керәм.
Касса.
Басам чиратка.
«Менә җиттем инде», – дип торганда,
Бер милиционер килә каршыма,
Караш ташлый буй-сыныма минем,
Торышыма, өстем-башыма.
Үзе шунда мине читкә алып:
– Кичен йөрү сиңа ярамый,
Балакаем, бар, өеңә кайт! – ди,
Егет икәнемне аңламый.
Алай итеп, болай итеп карыйм,
Аңлаталмыйм үзенә һич кенә;
Нишләтим соң, янда паспорт та юк,
Бар хикмәте – буем кечкенә.
Кайчак шулай клубларга барам,
Чибәр-чибәр кызлар күргәлим,
Артларыннан тәпи-тәпи генә
Эзләренә басып йөргәлим.
Берсе шунда бер үк каравында
Үзәгемне өзеп җибәрә;
Бар уйларым, тополь мамыгыдай,
Искәрмәстән аңа иярә.
Мин белергә телим исемен аның,
Кем икәнен, кайда, нишләвен...
Хатым аша ныклап сүз куешам
Очрашырга әйтеп кичләрен.
Барам.
Кыз да килә,
Тик күрүгә,
Күзләремә текәп күзләрен:
– Ник абыең килмәде соң? –
Дип кырт кисә шунда сүзләрен.
Алай итеп, болай итеп карыйм,
Аңлаталмыйм үзенә һич кенә;
Нишләтим соң, янда паспорт та бар,
Бар хикмәте – буем кечкенә.



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 3 (1928) март 2023
Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.03.2023 ел.
Тираж – 2590 Заказ С-0469
Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
16+
Бәясе ирекле

Уйна да, уйла да!

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ГАЗИНУР ...
ФРОНТОВИК-ШАГЫЙРЬ НУРИ ...
ЖЫРЧЫ ... БИКТАҺИРОВ
ДҮРТ АЯКЛЫ КАВАЛЕРИЯ СУГЫШЧЫСЫ
ЭСТРАДА ЖЫРЧЫСЫ ...
"...ЕГЕТЛӘР"
НОТА
"КАРА ... КИЛӘ СӨЙРӨЛЕП"
...-СУ
"КҮПТӘН ... (-2), КҮПТӘН ОЧРАШКАН ЮК"
ТӨССЕЗ БУЯУ(-1)
... ТОРМЫШ
ИСЛАМ ...
"... ЯФРАКЛАРЫ ШАУЛАВЫН..."
"ӘЛДЕРМЕШТӘН ӘЛМӘНДӘР"
ШАГЫЙРЬ ... КАСЫЙМОВ
ШАГЫЙРЬ ... ФӘЙЗУЛЛИН
КӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ СЕБЕРДӘ ШӘҺӘР
АРМИЯГӘ ...!
КОСМОНАВТ
"СУТЫЙ"
ТАРТТЫРЫЛГАН ЯРМА
МАРШАЛ НИКОЛАЙ ...
ИГЕНЧЕ ИГЕН ...
РУС РӘССАМЫ
"ТУГАН ..."
АНТОНОВ САМОЛЁТЫ
"ЗАМАНАЛАР ... ЕЛЛАР ЯБЫК"
ЧЫРШЫ БОТАГЫ
КӨЧ-...
ТУПОЛЕВ САМОЛЁТЫ
ВАТАН ...
АДМИРАЛ ФЁДОР ...
ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН ...
МАРШАЛ СЕРГЕЙ ...
ЭРЕ — ...
...(-1) АЧНЫ АҢЛАМАС
ЖИҢҮ МАРШАЛЫ
БОЛГАРИЯДӘ КУРОРТ

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Хатын-кызның сумкасында нәрсә юк?

2. Ир белән хатынның тату яшәве ничек була?

3. Очрашуга килгән кыз белән очрашуга килмәгәне арасында нинди аермалык бар?

4. Ни өчен вәгъдә ителгәнне өч ел көтәләр?

5. Нәрсә ул банк?

6. Вегетарианнар кемнәр алар?

7. Әкият чынбарлыктан нәрсәсе белән аерыла?

ЖАВАПЛАР

1. Буш урын. 2. Хатыны берни сорамыйча, ә ире беркайчан да каршы килмичә яшәү. 3. Килмәгәне кәефегезне генә бозарга мөмкин, ә килгәне – бөтен гомерегезне. 4. Чөнки, Россия Федерациясенең 196 нчы ГК статьясы нигезендәге дәгъва гаризасының өч еллык срогы бетә. 5. Хезмәт хакыгыз акчага мохтаҗлык тоймас өчен житсә, банкта сезгә бик рәхәтләнеп акча биреп торалар. 6. Колбасаны иттән тора дип уйлаучылар. 7. Әкияттә бакага өйләнсәң, ул патшабикә булып чыга. Чынбарлыкта – киресенчә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чайнвордны чишегез, номерланган шакмакларда жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 2 нче санында басылган чайнвордның тикшерү сүзе – **«БИК ЕРАКТА ИДЕК БЕЗ»**


Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ, (Чаллы),
Р. САФИН (Балык Бистәсе р-ны, Полянка ав.),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан),

Җиңүчебез – Урта Тигәнәледән **Бәдретдин ШӘЙХЕТДИНОВ!**

Кызлар йөрәгенә ут ягучы – Валерий Тарасенко





Александр АЛЁШИН

КОНКУРС

«Галәм гүзәле» дип, и чөйделәр,
Җиңеп кайткач бәйге-ярыштан.
...Нинди «галәм»?!
Катнашмагач анда,
Ичмасам, бер кызый Марстан?

